Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.6 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексының 3.6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7–8 (I өлеш), № 9–10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1–2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.6 статья. **Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу**

Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен –

гражданнарга – ике меңнән биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән утыз мең сумга кадәр; юридик затларга илле меңнән ике йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

Ел дәвамында шул ук гамәлләрне кылган (гамәл кылмаган) өчен –

вазыйфаи затларга – утыз меңнән илле мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән биш йөз мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 июне
№ 30-ТРЗ